ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2021 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап хакында

2021 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турындагы хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турындагы хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Хисап палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

финанс-икътисадый вәзгыять начарлану куркынычы булган шартларда, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчаларыннан файдалануга контрольлек иткәндә, оешмаларга, индивидуаль эшкуарларга дәүләт ярдәме чараларын һәм субсидияләр бирүне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чыгымнарның нәтиҗәлелеген һәм сакчыллыгын бәяләү мәсьәләләренә аеруча игътибар бирергә;

Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына һәм аларга үзгәрешләргә финанс-икътисадый экспертиза, программа чараларының максатчан индикаторларына ирешүне анализлау эшен дәвам итәргә;

бюджет процессына, Татарстан Республикасында дәүләт милкенә идарә итүгә һәм аның белән эш итүгә тышкы дәүләт финанс контролен камилләштерү эшен дәвам итәргә;

Татарстан Республикасында илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга һәм илкүләм максатларга ирешүгә контрольне дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәмммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 15 июне
№ 1470-VI ДС